Важашур авыл жирлеге Советы

КАРАР

18 декабрь, 2023 ел №32

Важашур авыл Советының 2018 елның 27 февралендагы 3 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Важашур авыл Советы муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Важашур авыл Советы карар бирде:

1. Важашур авыл Советының 2018 елның 27 февралендагы 3 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Важашур авыл Советы муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә ((2018 елның 07 ноябрендәге24 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 10 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 7 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 5 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 11 номерлы, 2023елнын 27 апрелендагы 9 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Важашур авыл җирлеге башлыгына класслы чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл жирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Важашур авыл Советы башлыгы П.Л. Иванов